**МИНИСТЕРСТВО ПРОСВЕЩЕНИЯ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ**

**Министерство образования Республики Мордовия**

**Ромодановский муниципальный район**

**МБОУ "Белозерьевская средняя общеобразовательная школа"**

| РАССМОТРЕНО | СОГЛАСОВАНО | УТВЕРЖДЕНО |
|---|---|---|
| Методобъединение | Зам.директора по УВР | Директор школы |
| ________________________ | ________________________ | ________________________ |
| Абдрашитова Л.Р. | Манеева Л.Р. | Киреева Э.И. |
| Протокол №1 от «30» августа2023 г. | Протокол №1 от «30» августа2023 г. | Приказ № 93 от «31» августа2023 г. |

**Рабочая программа**
**учебного курса « Родной (татарский) язык»**
**в 3 «А» классе**
**УМК «Школа России»**

**Составитель:**
**Бикмаева Гульсина Няиловна**
**учитель начальных классов**
**МБОУ "Белозерьевская СОШ”**

**Белозерье**
**2023 г**

## АҢЛАТМА язуы

Программа нигезенә Россия, Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыкларының мәктәпләрдә башлангыч белем алу стандартлары салынды.
Программа түбәндәгедәүләтдокументларынанигезләнепязылды:
1. «Татарстан Республикасыдәүләттелләреһәм Татарстан Республикасында башка телләртурында» Татарстан Республикасы Законы (2004 ел,1 июль).
2. «2004-2013 нчеелларга Татарстан Республикасыдүләттелләренһәм Татарстан Республикасында башка телләрнесаклау, өйрәнүһәмүстерүбуенча Татарстан РеспубликасыДәүләтпрограммасы» (2004 ел, 11 октябрь).
3. Россия Федерациясенең 309-ФЗ номерлы Законы (2007 ел, 1 декабрь).
4. Татар теленнәнгомумибашлангычбелембирүнеңдәүләт стандарты.-ТР Мәгарифһәмфәнминистрлыгы, Казан, 2008.
5. Татар телендәбашлангычгомумибелембирүмәктәпләреөчен татар теленнән программа (1-4 нчесыйныфлар). Казан: «Мәгариф» нәшрияты, 2010.

Программанынисеме: 3 нчесыйныфөчен татар теленнәнэшпрограммасы
Программа ничәсәгатькәисәпләнелгән: 68 сәгатькә
Дәреслек:дүртьеллыкбашлангыч татар мәктәбенең 3нче сыйныфыөчендәреслек (2 кисәктә, Казан, “Мәгариф”нәшрияты, 2009ел) Татарстан РеспубликасыМәгарифһәмфәнминистрлыгытарафыннанрасланган.
Авторлары : Харисов Ф.Ф., Хисамова Ф.М., Харисова Ч.М. Татар теле. – Казан: Мәгариф, 2006.
Программа дәрәҗәсе: база дәрәҗәсендә
Ниндиукучыларгатөзелгән:уртачаукыйторганбалаларныисәпкәалыптөзелгән.
Программа ниндияшьүзенчәлекләренкүздәтотыптөзелә: 3 нче класс укучыларыөчен 9- 10 яшьлекбалаларгатөзелгән.
Башка предметларбеләнбәйләнеше: тел чараларының төрле жанрдагы әсәрләрдә кулланылу үзенчәлекләрен күрә белү;
тел материалын уку материалы белән бәйләп, татар теленең байлыгына һәм матурлыгына хөрмәт тәрбияләү;
татар һәмрус телләренең уртак һәм аермалы якларын күрә белү, сөйләм барышында ике тел чараларын бутамау;
татар теленә рус теленнән һәмрус теле аша башка телләрдән кергән лексик чараларны аеруга игътибар юнәлтү;
татар теленнән алган белемне башка фәннәрне үзләштерүдә файдалана белү.
**Программаныңхарактерлыяклары (аерымяклары):**
Типик, авторлык һәм башкалар: программа ТР мәктәпләре укытучыларыныкы үрнәгендә төзелде, типик.
Программа эчтәлегендәге үзгәрешләр: кабатлау дәресе өстәлү сәбәпле, һәр бүлек 1 сәгать арттырылды.

Укыту-тәрбия бирү методлары, алым, форма һәм технологияләре ничаклы һәм ничә тапкыр үзгәрсә дә, аларның нигезе — туган тел үзгәрешсез, универсаль чара булып кала. Гасырлар уза, буыннар алмашына, ә тел һаман мәгърифәткә һәм кешенең рухи үсешенә хезмәт итә. Тел милләтне уртак максатлы тормыш эшчәнлеге һәм аралашу мохитенә берләштерә. Кеше шул эшчәнлектә һәм мохиттә катнашып, аралашып тәрбияләнә, аң-белемен үстерә һәм үзендә чын кеше сыйфатлары булдыра.

Шәхес — тел һәм мәдәният бәйләнеше үзәге, шуңа күрә телдә гәүдәләндерелгән шәхес турында гына сүз алып барырга мөмкин. Бала тел аша тирә-якны өйрәнә һәм үзен башкалар арасында таныта. Халык үз фәлсәфәсендә телнең әһәмиятен бик төгәл бәяләгән: «Теле бар,— димәк, кеше».
Тел дәресләре балаларны халкыбызның рухи-әхлакый идеалларына китерергә, аларда югары сөйләм культурасы формалаштырырга, иҗади сәләтләрен үстерергә, мөстәкыйль уйларга һәм эшләргә омтылышын канәгатьләндерергә тиеш.

Мәктәпкә кергәнче үк, бала ана телендә сөйләшә белә, ләкин ул телне әле аңлы рәвештә кулланмый, ана телендә сөйләү — аның өчен табигый хәл.
**<u>Программаныңмаксаты</u>**— Татар теленнәнгомумибашлангыч белем бирүнең максатлары:
татар телендә аралашу күнекмәләре булдыру;
тел чараларын аралашу эчтәлегеннән чыгып сайлый белергә өйрәтү;
тел белеменең фонетика,лексика, грамматика бүлекләре буенча башлангыч белем бирү, өйрәнелә торган тел берәмлекләрен тикшерә һәм куллана белү күнекмәләрен булдыру;
сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләре буенча күнекмәләр формалаштыру;
укучыларда татар теленә хөрмәт һәм ихтирам тәрбияләү, телнең чисталыгын, дөреслеген саклау, телне, халыкның рухи мирасын өйрәнүгә кызыксыну уяту.

укучыларны ана телен төшенеп, аңлап, закончалыкларына таянып һәм сөйләм ситуацияләренә туры китереп кулланырга өйрәтү. Моның өчен сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрен дә (тыңлау, сөйләү, уку һәм язу) үстерергә кирәк. Дәреслекләрдә материал коммуникатив юнәлешле итеп, ә укучыларның танып белү эшчәнлеге аралашу формасында оештырыла.
<u>Программа түбәндәге бурычларны</u> хәл итүгә юнәлтелә:
-укучыларда сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрен үстерү һәм телне аралашу чарасы буларак барлык ситуацияләрдә кулланырга өйрәтү;
-аралашу һәм танып белү чарасы булган телне аңлы үзләштерүгә ирешү;
-балаларны текст, китап белән эш итү алымнарына өйрәтү;
-аралашу осталыгы һәм иҗади сәләт арасында бәйләнеп булдыру;
-укучыларның образлы, логик фикерләвен үстерү, аларда аралашу культурасы күнекмәләре тәрбияләү.

Моның өчен тел дәресләрен танып белүгә юнәлешле итеп балаларның актив эшчәнлегенә таянып оештырырга кирәк, һәр тема түбәндәге эзлеклелектә өйрәтелә:
-сөйләмне, текстны тикшереп, өйрәнеләчәк теманың әһәмияте күрсәтелә, проблема куела, башлангыч гипотеза әйтелә;
-укучылар үзләре «ачкан» кагыйдәне, төшенчәне, эш алымын мөстәкыйль рәвештә әйтәләр;
-дәреслекләргә таянып, укучылар тарафыннан ясалган ачышларга төгәллек һәм тулылык кертелә;
-тема буенча алган белемнәрне куллануга күнегүләр үткәрелә.

Эшнең шушындый эзлеклелектә оештырылуы телне аңлауда эчтәлектән формага күчәргә мөмкинлек ача, икенче төрле әйткәндә, лексикадан грамматикага, фонетикадан грамматикага, сөйләмнән телгә, телдән сөйләмгә, аралашу ситуациясендә әйтелгәнне аңлаудан үз сөйләмеңне мөстәкыйль рәвештә төзүгә салмак күчеш ясарга мөмкинлек бирә.
**<u>Башлангыч сыйныф укучыларының белем, осталык һәм күнекмәләренә төп таләпләр (уку елы башында)</u>**
**Укучылар түбәндәгеләрне белергә тиеш:**
сөйләмдәге авазлар
өйрәнелгән сүз төркемнәренең лексик һәм грамматик билгеләре
сүзнең мәгънәле кисәкләре

гади һәм кушма җөмлә, җөмләдә баш һәм иярчен кисәкләрнең (терминнарын әйтмичә) билгеләре
сүзтезмә билгеләре.
**Укучылар чагыштыра һәм аера белергә теш**
аваз һәм хәреф
сузык һәм тартык авазлар
калын һәм нечкә сузыклар
яңгырау һәм саңгырау тартыклар, парлы һәм парсыз яңгырау һәм саңгырау тартыклар
исем, сыйфат, фигыль, заталмашлыклары, кисәкчә
тамырһәмкушымча, сүзясагычһәмсүзтөрләндергечкушымчалар
җөмләләрнеңәйтелүмаксатыбуенчатөрләре
җөмләнең баш һәмиярченкисәкләре (төрләргәбүлмичә)
җөмләбеләнсүзтезмәнеңаермасы
тиңдәшкисәклеҗөмләләр.
<u>Укучылардатүбәндәгебелем, осталыкһәмкүнекмәләребулыргатиеш (укуелыазагында):</u>
сүзләрнеиҗеккәбүлү
сүздә аваз һәм хәреф санын чагыштыру
ешкулланылышлысүзләрне орфоэпия нормаларына туры китерепәйтү
алфавитныкулланабелү (сүзлек, каталог беләнэш)
сүзләрнеюлданюлгакүчерү
өйрәнелгәнсүзтөркемнәренеңҗөмләдәге ролен күрсәтү
сүзнеңмәгънәлекисәкләренһәмясалышынбилгеләү
сүздәгеясагычһәмтөрләндергечкушымчаларныбилгеләү
фигыльләрдәгезат – сан кушымчаларынаеру
- җөмләдәгесүзләрбәйләнешеначыклау
гадиҗөмләдәтиңдәшкисәкләрне табу
75-80 сүзлетекстныачыкһәмтөгәлитепкүчерепһәмишетепязу.
**Түбәндәге орфограмма һәмпунктограммаларкертелә:**
-җөмлә башында һәм ялгызлык исемнәрдә баш хәреф;
-сүзләрдә о—ы, ө—е сузыклары;
-ъ һәм ь хәрефләре кергән сүзләр;
-кушма һәм парлы сүзләр;
-саңгырау һәм б, в, г, д тартыкларына беткән исемнәрдә
- килеш кушымчалары; -
борын авазларына беткән исемнәрдә килеш кушымчалары;
-сыйфатларда чагыштыру, артыклык һәм кимлек дәрәҗәсе
-формаларының язылышы;
-җөмлә ахырында тыныш билгеләре (нокта, сорау һәөндәү билгеләре);
- тиңдәш кисәкләр янында тыныш билгеләрен куя белергә тиеш
<u>Практик юнәлеш:</u>диктант, изложение, сочинениеләрнекагыйдәләрнеаңлаганхәлдәязабелү. Алган теоретик белемнекүнегүләрдәфайдаланууосталыгынаирешү.
<u>Төрлеэшләрнебәяләүкритериесе</u>: үзләштерүнең, эшнеңдөреслегенәкарапбилге кую, билгенебилге кую нормаларына туры китерү.

Технология, аның бурычлары, көтелгән нәтиҗә:    яңа педагогик- психологик технологияләр элементларын файдаланып, эзләнү, өйрәнү, кабатлау аша белем бирү. Өзлексез белем бирүгә нигезләнеп, төрле эшчәнлек алымнарын клланып эш оештыру. Үз фикерен әйтә белергә, стандартлар буенча куелган таләпләр үтәлерлек дәрәҗәдә белем алуга ирешү.
Дәрестә төп методлар: өлешчә эзләнүчән,  тормыш тәҗрибәсенә нигезләнеп аңлатмалы укыту методы,әңгәмә, аңлату,сорау, биремне чишү, дәреслек белән эшләү, интерактив укыту, коммуникатив, тикшерү методлары.
Укучыларның эшчәнлеген оештыру формасы: парлап, коллектив һәм шәхси якын килү алымнары.

**3 нче сыйныфның татар төркеме өчен “татар теле”предметыннан календарь – тематик  план.**

| № п/ | Өйрәнеләсе бүлек, уку материалының | Календарь срок | Планлаштырылган   нәтиҗә. |
|---|---|---|---|
| | | | |

| п | темасы. | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | план | факт | |
| | **1 бүлек--2 нче сыйныфта үткәннәрне кабатлау . 13 сәгать** | | | |
| 1 | Туган тел турында әңгәмә. | | | “Туган телем-иркә гөлем” темасы буенча сөләшү. Г.Тукайның шигырьләрен искә төшерү.<br>Хикәя төзү “Туган телем – иркә гөлем” |
| 2 | Авазлар һәм хәрефләр. | | | Хәрефләрнең укылышын яттан белү, һәр хәрефне дөрес әйтеп укый белү.<br>Аваз һәм хәрефләрне аера белү. |
| 3 | Сузык һәм тартык авазлар. | | | Калын һәм нечкә сузыкларны аерып, татар телендәге сүзләрнең сингармо-<br>низм законына буйсынуын яки буй-<br>сынмавын аңлату.<br>Яңгырау һәм саңгырау тартык авазларны аеру.<br>Татар теленең үзенчә- лекле авазлары кергән сүзләрдәге аваз һәм хәрефләрне аерып әйтә белү. |
| 4 | Калынлык (Ъ) һәм нечкәлек (Ь) билгеләре. | | | Ъ һәм ь хәрефләре булган сүзләрне дөрес уку һәм язу. |
| 5 | Сүзләрне иҗекләргә аеру. | | | Сүздәге иҗекләрнең саны сузык авазларга бәйле булуын аңлау.<br>Сүзлек диктан- ты №1 |
| 6 | Сүз басымы. | | | Сүз басымын дөрес билгели белү. Татар телендә басымның соңгы иҗеккә төшүен аңлау.<br>Татар телендә сүз басымын кую, рус сүзләре белән чагыштырып күрсәтү.<br>Һәр дәрестә дәреслек белән эшләү күнекмәләре өстендә эш. |
| 7 | **Кереш диктант.** | | | Диктант №1 Грамоталы язу күнекмәләрен тикшерү. |
| 8 | Фонетик анализ ясау. | | | Сүзләрне иҗекләргә бүлеп, басымны билге- ләү, авазлар һәм хә- рефләр санын әйтү |
| 9 | Сүз төркемнәре. Исем. | | | Исем кем? нәрсә? со- рауларына җавап бирә. Исемнең мәгънәсен аңлап, җөм- лә эченнән табып әйтү.<br>Исемнең берлек һәм күплек сан форма- ларын аерып кулла- на белү. |
| 10 | Фигыль. | | | Фигыльнең заман кушымчаларын билгеләү.<br>Фигыльнең мәгънәсен аңлап, җөмлә эченнән табып әйтү. |
| 11 | Сыйфат. | | | Сыйфатларның сыйфатланмышка иярү буенча белемнәрен ныгыту.<br>Сыйфатның мәгънәсен аңлап,җөмлә эченнән табып әйтү. |
| 13 | Җөмләнең баш | | | Җөмләнең баш кисәкләрен билгеләү, аларның урнашу тәртибен аңлату. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | кисәкләре. | | | |
| **2 бүлек-- Сүз. 24сәг** | | | | |
| 14 | Сүз. Туры һәм күчерелмә мәгънәле сүзләр. | | | Сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәләрен аерырга өйрәтү. |
| 15 | Туры һәм күчерелмә мәгъ- нәле сүзләр. | | | Сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәләрен аерырга өйрәтү |
| 16 | **Хикәя язу. Л.А.Фәттахов “Әни күрмәгәндә”** | | | Фикерләрен эзлеклелеккә салып, кечкенә хикәя төзү.<br>Хикәя язу. |
| 17 | Бер һәм күп мәгънәле сүзләр. | | | Бер мәгънәле сүзләрне күп мәгънәле сүзләрдән аера белү. |
| 18 | Синонимнар. | | | Уртак мәгънәле, бер – берсеннән мәгънә төс- мерләре һәм язылышы белән генә аерылып торучы сүзләрне аерып тану.<br>Синоним сүзләрне дөрес билгеләп, аларны сүз- тезмә һәм җөмлә төзегәндә дөрес куллану. |
| 19 | Синонимик оялар төзү. | | | “Әхлакый хәзинәләр” темасы буенча синонимик оялар төзү. |
| 20 | Омонимнар. | | | Омонимнар турында тшенчә бирү, аларны аера белү күнекмәләре формалаштыру. |
| 21 | **Контроль диктант.** | | | Укучыларның алган белемнәрен тикшерү һәм камилләштерү.<br>Диктант №2 |
| 22 | Хаталар өстендә эш. | | | Кагыйдәләргә нигезләнеп хаталы сүзләрне тикшерү, яздыру, җөмләләр төзү. |
| 23 | Антонимнар. | | | Капма - каршы мәгънәле сүзләр белән таныштыру.<br>Антоним сүзләрне дөрес билгеләп, аларны сүзтезмә һәм җөмлә төзегәндә дөрес кулланырга өйрәтү. |
| 24 | **Сочинение “Туган ягымда көз”** | | | Укучыларның фикерләү сәлатен, бәйләнешле сөйләм телен үстерү , сүзлек байлыгын арттыру өстендә эшне дәвам итү.<br>Сочине-ние №1 |
| 25 | Сүзлекләр белән эшләү | | | Төрле сүзлекләрне куллана белү күнекмәләре өстендә эшне дәвам итү.<br>Орфографик, аңлатмалы сүзлекләр белән эшләү. |
| 26 | Сүз бүлеген кабатлау һәм ныгыту. | | | Укучыларның фикерләү сәлатен, бәйләнешле сөйләм телен үстерү , сүзлек байлыгын арттыру өстендә эшне дәвам итү.<br>Сүзлек диктанты №2 |
| 27 | Тамыр. | | | Тамыр – сүзнең төп мәгънәсен белдерүче кисәк .<br>Сүзләрең тамырын табарга өйрәтү. |
| 28 | Кушымча. | | | Кушымча тамырга ялганып килә торган кисәк.<br>Кушымчаларны тамырдан аерырга өйрәтү. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 29 | Тамырдаш сүзләр. | | | Тамырдаш сүзләрне төрле ясагыч кушымчалар ярдәмендә бер үк тамырдан ясау.<br>Тамырдаш сүзләрнең мәгънәләре арасында бәйләнеш саклау. |
| 30 | Кушымчалар һәм аларның төрләре. | | | Ясагыч һәм мөнәсәбәт белдерүче кушымчалар була.<br>Ясагыч һәм мөнәсәбәт белдерүче кушымчаларны дөрес куллану. |
| 31 | Сүз ясагыч кушымчалар. | | | Сүз ясагыч кушымчалар ярдәмендә яңа сүзләр ясау. |
| 32 | Мөнәсәбәт белдерүче кушымчалар. | | | Мөнәсәбәт  белдерүче кушымчалар исемнәрдә – күплек сан, фи- гыльләрдә заман кушымчалары. Алар эш- хәл арасындагы мөнә- сәбәтләрне белдерә.<br>Мөнәсәбәт белдерүче кушымчаланы табарга өйрәтү. |
| 33 | Бер тамырга берничә кушымча ялгау. | | | Татар телендә тамырга башта ясгычкушымча, аннары мөнәсәбәт белдерүче кушымчаларның ялгануын аңлау. |
| 34 | Тамыр һәм ясалма сүзләр. | | | Тамыр сүзгә турыдан- туры мөнәсәбәт бел- дерүче кушымча ялганырга мөмкин.Ясалма сүзләр тамырга ясагыч кушымча ялганып ясала.<br>Тамыр һәм ясалма сүзләрнең ясалышын аңлату, сүз төзелеше ягыннан анализ ясый белү күнекмәләрен булдыру. |
| 35 | Кушма сүзләр. | | | Кушма сүзләр ике сүз кушылып ясала.Алар һәрвакыт кушылып языла.<br>Кушма сүзләрнең ясалышын аңлату, язылышын күзәтү, сүз төзелеше ягыннан анализ ясый белү күнекмәсен булдыру. |
| 36 | Парлы сүзләр. | | | Парлы сүзләр, ике сүзне теркәп, бер мәгънә белдерә. Алар сызыкча аша языла.<br>Парлы сүзләрнең ясалышын аңлату, язылышын күзәтү, сүз төзелеше ягыннан анализ ясый белү күнекмәсен булдыру. |
| 37 | Сүз төзелеше бүлеген кабатлау. | | | Укучыларның алган белемнәрен тикшерү һәм камилләштерү. |
| **3  бүлек – Морфология – 21 сәг** | | | | |
| 38 | Исем. Исемнәрнең берлек һәм күплек формалары. | | | Исем буенча белемнәрне барлау, ныгыту. |
| 39 | Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. | | | Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр булуын аңлау.<br>Ялгызлык һәм уртаклык исемнәрне танып белү, дөрес куллана белү күнекмәләрен булдыру. |
| 40 | Исемнәрнең килеш белән төрләнеше. | | | Исемнәрне берлектә һәм күплектә килеш белән төрләндерә белү. |
| 41 | **Контроль диктант.** | | | Укучыларның алган белемнәрен тикшерү һәм камилләштерү.<br>Диктант №3 |
| 42 | Хаталар өстендә эш. | | | |
| 43 | Баш килеш, иялек килеше. | | | Исемнәрне баш һәм иялек килешләрендә төрләндерә белү күнекмәләре булдыру. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 44 | Юнәлеш килеш, төшем килеше. | | | Юнәлеш килешендә килгән килгән исем- нәргә –га, -гә, -ка, -кә, төшем килешендә килгән исемнәргә –ны, -не кушымчалары ялгана. |
| 45 | Чыгыш килеш, урын-вакыт килеше. | | | Исемнәрне чыгыш  һәм урын-вакыт килешләрендә төрләндерә белү күнекмәләре булдыру. |
| 46 | Алмашлык. Зат, сорау алмашлыклары. | | | Зат алмашлыклары сөйләшүдә катнашучы затларны- сөйләүче- ләрне, тыңлаучылар-ны, алар турында сүз барган зат, предметларны белдерәләр.<br>Зат һәм сорау алмашлыкларын башка сүз төркеменнән аера белү. |
| 47 | Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше. | | | Зат алмашлыкларын килеш белән төрләндерү. |
| 48 | Сорау алмашлыклары. | | | Сорау алмашлыкларын диалогик һәм монологик сөйләмдә куллану. |
| 49 | Фигыль. Фигыльләрнең заман белән төрләнеше. | | | Фигыль  турында белемнәрне барлау. |
| 50 | Хәзерге заман хикәя фигы- льнең зат- сан белән төрләнеше. | | | Фигыльләр зат- сан белән төрләнәләр.<br><br>Хәзерге заман хикәя фигыльләрне зат- санда төрләндерү |
| 51 | **Изложение.** | | | Укучыларның фикерләү сәлатен, бәйләнешле сөйләм телен үстерү , сүзлек байлыгын арттыру өстендә эшне дәвам итү.<br>Изложение №1 |
| 52 | Сыйфат. | | | Сыйфатларны башка сүз төркемнәреннән аеру. |
| 53 | Синоним сыйфатлар. | | | Синоним сыйфатларның мәгънәләре охшаш була.<br>Синоним сыйфатларны текстан табу, сөйләмдә дөрес һәм урынлы куллану. |
| 54 | Антоним сыйфатлар. | | | Антоним  сыйфатларны текстан табу, сөйләмдә дөрес һәм урынлы куллану. |
| 55 | Сыйфатларның исемне ачыклап килүе, җөмләдәге роле. | | | Сыйфатларның исемне ачыклап килүен,җөм-ләдәге ролен аңлау.<br>Рус телендә сыйфатланмышка карап, сыйфатка төрле кушымчалар ялгана. |
| 56 | Сан турында төшенчә. | | | Предметның санын, исәбен белдереп, ничә?,ничәнче?,<br>ничәү? ничәшәр?,<br>ничәләп? сорауларына җавап булган сүз төркеме сан дип атала |
| 57 | **Контроль диктант.** | | | Укучыларның алган белемнәрен тикшерү һәм камилләштерү.<br>Диктант №4 |
| 58 | Хаталар өстендә эш. | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **4 бүлек – Синтаксис – 12 сәг** | | | | |
| 59 | Сүзтезмә һәм җөмлә. | | | Сүзтезмә предметлар- ларның, эш-хәрәкәтнең мәгънәсен төгәл- рәк атый.<br>Сүзтезмә иярүче һәм ияртүче сүздән төзелә. |
| 60 | Хикәя җөмләләр. | | | Хикәя җөмлә тыныч тавыш белән әйтелә. Аның ахырында нокта куела. |
| 61 | Сорау җөмләләр. | | | Сорау  җөмлә сорау интонациясе  белән әйтелә. Аның  ахырында сорау билгесе куела. Сорау җөмләдә кем?, нәрсә?, нинди?, нигә?, ни өчен? кебек сүзләр куела. |
| 62 | Өндәү җөмләләр. | | | Өндәү  җөмлә күтәренке тавыш белән әйтелә һәм эш кушуны, боеруны, үтенүне белдерә. Аның ахырында өндәү билгесе куела. |
| 63 | Хикәя, өндәү, сорау җөмләләрне гомумиләш- тереп кабатлау. | | | Хикәя, өндәү, сорау җөмләләрне аеру һәм аларны дөрес интонация белән укып, тыныш билгеләрен дөрес кую күнекмәләрен формалаштыру. |
| 64 | Җөмләнең баш кисәкләре<br>Ия. | | | Ия баш килештәге исем яки алмашлык белән белдерелә.Татар телендә гадәттә ия хәбәрдән алда килә.<br>Җөмлә кисәге һәм сүз төркемнәре дигән төшенчәләрне аера белү. |
| 65 | Хәбәр. | | | Хәбәр фигыль һәм сыйфат белән белдерелә.Хәбәр җөмләнең ахырында килә. |
| 66 | Аергыч. | | | Аергыч- җөмләнең иярчен кисәге. Ул нинди?, кайсы?, ничәнче?, кемнең?, нәрсәнең? сорауларына  җавап бирә. Гадәттә аергыч сыйфат белән белдерелә.<br>Җөмләнең баш кисәкләрен билгеләү, аларның урнашу тәртибен аңлату. |
| 67 | **Контроль диктант.** | | | Укучыларның алган белемнәрен тикшерү һәм камилләштерү.<br>Диктант №5 |
| 68 | Хаталар өстендә эш. | | | Кагыйдәләргә нигезләнеп хаталы сүз- ләрне тикшерү, яздыру, җөмләләр төзү. |
| | **Итого 68 сагать** | | | |